ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2021 Олы Кайбыч ав. № 401

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 апрелендәге 211 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 апрелендәге 211 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15.4 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасының саклау корылмаларына һәм аларның техник системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм тиешле максатларда файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту, саклап калу;»;

1.2. 15.5 пунктны түбәндәге эчтәлекле 5 абзац белән тулыландырырга:

«билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә кертелгән территорияләрнең демаскацияләүче билгеләрен киметү буенча инженер-техник чаралар үткәрү.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров